Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Клементейкино авылы башкарма комитеты

КАРАРЫ

20 август 2021 ел № 6

Әлмәт муниципаль районы Клементейкино
авылы башкарма комитетының
2018 елның 31 июлендәге
4 номерлы «2018- 2035 елларга
Татарстан Республикасы Әлмәт
муниципаль районы Клементейкино
авыл җирлегенең социаль
инфраструктурысын комплекслы
үстерү Программасын раслау турында»гы
карарын үз көчен югалткан дип тану
турында

Әлмәт шәһәр прокуратурасы бәяләмәсенә һәм программаны гамәлгә ашыруга финанслау чыганаклары булмау турында Әлмәт муниципаль районының контроль-хисап палатасы бәяләмәсенә, шулай ук Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының норматив хокукый актларны законнарга туры китерү турындагы телдән бирелгән күрсәтмәсенә нигезләнеп ,

Клементейкино авылы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Клементейкино авылы башкарма комитетының 2018 елның 31 июлендәге 4 номерлы «2018- 2035 елларга Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Клементейкино авыл җирлегенең социаль инфраструктурысын комплекслы үстерү Программасын раслау турында» гы карары үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Әлмәт районы, Клементейкино авылы, Центральная урамы, 38А йорт; Багряж авылы, Кызыл Йолдыз урамы, 38А йорт; Яңа Чишмә авылы, Гафиятуллин урамы, 3А йорт территориясендә урнашкан махсус стендларда игълан итәргә, шулай ук «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU), Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет»челтәрендә урнаштырырга

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң (халыкка җиткерелгәннән) үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Клементейкино авылы башкарма
комитеты җитәкчесе Л.Э.Языков